**БОЛЬШЕМЕНГЕРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘҢГӘР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422008, Республика Татарстан, Атнинский район, с.Большой Менгер, ул.Советская, д.8, т.3-46-25

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31.01.2023 ел.** **№ 1**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммммәтен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы “Җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы “Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында “Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 нче номерлы “ 2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әтнә мунципаль районының Олы Мәңгәр авыл җирлегендә № 1 нче һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәт бәясен 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм 2023 елның 1нче февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында»гы карарын 2023 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә
муниципаль районы Олы Мәңгәр
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Ф.Филатова

СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1610002353

Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетының 2023 елнын 31 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 5160,43 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 623,19 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2009,86 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетының 2023 елнын 31 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 280,43 |
| 3. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 4880,00 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 623,19 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2009,86 |
| Барлыгы | 7793,48 |